| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«13» октябрь 2025ел № 143

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 гыйнварындагы 21 номерлы «Теләче муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Теләче районы прокуратурасының 2025 елның 18 сентябрендәге 02-01-08-2025/346-25-20920037 номерлы күрсәтмәсен карап, «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен, хезмәт дәрәҗәсен күтәрү, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 гыйнварындагы 21 номерлы «Теләче муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-891 номерлы «Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча Республика ведомствоара комиссиясе мәсьәләләре» Указының 3 пунктын исәпкә алып» сүзләрен «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен, хезмәт дәрәҗәсен күтәрү, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин